КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 апрель г.Казань № 299

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән расланган Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 17 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 5 март, 138 нче; 2018 ел, 2 апрель, 200 нче; 2018 ел, 5 июнь, 425 нче; 2018 ел, 4 июль, 550 нче; 2018 ел, 8 декабрь, 1090 нчы; 2019 ел, 25 гыйнвар, 41 нче; 2019 ел, 1 март, 148 нче; 2019 ел, 24 апрель, 339 нчы; 2019 ел, 26 апрель, 347 нче; 2019 ел, 29 апрель, 350 нче; 2019 ел, 28 август, 711 нче; 2019 ел, 16 сентябрь, 838 нче; 2019 ел, 26 декабрь, 1216 нчы; 2020 ел, 10 гыйнвар, 1 нче; 2020 ел, 24 февраль, 138 нче; 2020 ел, 10 июль, 571 нче; 2020 ел, 5 август, 657 нче, 2021 ел, 10 март, 122 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Заемчы холдинг компаниясе структурасына кергән очракта, әлеге Тәртипнең 11, 12 пунктларында каралган документлар турыдан-туры Министрлыкка бирелә. Субсидияләр күләмен исәпләүне холдинг компаниясе җитәкчесе (алга таба - инвестор) килештерә.»;

14 пунктта «Идарә» сүзеннән соң «яисә инвестор» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин